ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 12 2018 елның 18 гыйнвары

# Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги үткәрү тәртибе турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1 пункты нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетын «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ исеменнән Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги заказчысы итеп билгеләргә;

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказын урнаштыру секторына (Т.В. Тарасов) торги оештыручы функцияләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтләр бирергә.

3. Расларга:

3.1. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм ксплуатацияләү хокукына торги үткәрү комиссиясе турында нигезләмә (1 нче кушымта);

3.2. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта);

3.3. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең типлаштырылган формасы (3 нче кушымта).

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында реклама конструкцияләрен (тышкы мәгълүмат чараларын) урнаштыру хокукына торги үткәрү турында» 2016 елның 10 февралендәге 105 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 18 нче гыйнвар
12 нче номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги уздыру комиссиясе турында нигезләмә

1. Түбән Кама муниципаль районында тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру хокукына торги үткәрү комиссиясе «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә торги үткәрү өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, «Реклама турында», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнары оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар, «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, башка норматив хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- торгида катнашу өчен гаризаларны карау һәм аукционда катнашучыларны сайлап алу;

- торгиларда катнашуга гаризаларны карау беркетмәсен, торги беркетмәләрен, шартнамә төзүдән баш тарту турында беркетмәне, гариза бирүчене яисә торгида катнашучыны торгида катнашудан чыгару турында беркетмәне алып бару;

- торги үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне үтәү.

4. Комиссия хокуклы:

- дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук профильле органнардан һәм предприятиеләрдән билгеләнгән тәртиптә эш өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән материалларны һәм документларны соратып алырга;

- комиссия утырышларын үткәрергә, комиссия компетенциясенә керүче барлык мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә һәм хат алышырга;

- бәйсез экспертларны, шул исәптән закон нигезендә сайланган экспертларны торги тәкъдимнәрен бәяләү өчен чакырырга.

5. Комиссиянең эш тәртибе.

5.1. Комиссия составы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе муниципаль акты белән раслана.

5.2. Комиссияне комиссия эшчәнлеге белән идарә итүче рәис җитәкли.

5.3. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

5.4. Комиссия сәркатибе комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә, утырыш беркетмәләрен һәм башка документларны рәсмиләштерә.

5.5. Әгәр утырышта комиссия составына керүче затларның 50% ы булса, комиссия тулы хокуклы булып санала.

5.6. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән катнашалар һәм комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалыйлар.

5.7. Торгида катнашу өчен гаризаларны карау нәтиҗәләре турында (гариза бирүчеләрне катнаштыру яки катнаштырудан баш тарту турында) карар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавыш бирүчеләр саны буенча кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Торги нәтиҗәләре турындагы карар торги нәтиҗәләре белән билгеләнә. Комиссия карарлары, шул исәптән торгида катнашу өчен гаризаларны карау нәтиҗәләре турында, торги нәтиҗәләре турында карарлар, җиңүчене билгеләү һәм башкалар комиссия утырышы протоколы белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 18 нче гыйнвар
12 нче номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торги әзерләү һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, «Реклама турында», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнары оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар, «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнләнгән.

II. Төп төшенчәләр

аукцион – аның барышында реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукын иң югары бәя тәкъдим иткән кеше сатып ала торган торги формасы;

ачык торги үткәрү комиссиясе (алга таба – Комиссия) - Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалану хокукына ачык торги үткәрүне оештыру өчен төзелгән коллегиаль орган;

торги заказчысы – ачык торги заказчысы буларак ул вәкаләт биргән орган исеменнән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты;

торги оештыручысы – ачык торги үткәрү инициаторы буларак ул вәкаләт биргән орган исеменнән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты;

торги катнашучысы - торгида катнашырга кертелгән юридик яки физик зат, шул исәптән шәхси эшмәкәр;

гариза бирүче - тәкъдим ителгән шартларда торгида катнашу өчен гариза биргән юридик яки физик зат, шул исәптән шәхси эшмәкәр;

аукцион турында документлар - торги оештыручысы тарафыннан әзерләнгән һәм торги предметы һәм аларны үткәрү шартлары турында мәгълүмат булган документлар комплекты;

гариза - гариза бирүче тарафыннан аукцион документлары таләпләренә туры китереп әзерләнгән документлар җыелмасы;

гаризаны кире кагу - торгида катнашу өчен гариза биргәннән соң гариза бирүченең торгида катнашудан баш тартуы;

гаризаны тәэмин итү - торгларда катнашу өчен гаризаны тәэмин итү сыйфатында акча кертү. гаризаны тәэмин итү күләме аукцион турындагы документларда билгеләнә.

III. Торгида катнашучыларның функцияләре

3.1. Торги заказчысы түбәндәге функцияләрне башкара:

- аукцион турында документлар эшләү өчен кирәкле гариза һәм документлар әзерли. Әзер документлар торгины оештыручыга бирелә;
- торги үткәрү турында карар кабул итә;
- Түбән Кама муниципаль районында реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү турында шартнамә төзи;
- үткәрелә торган торгины матди тәэмин итүне гамәлгә ашыра;
- торги үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

3.2. Торги оештыручысы түбәндәге функцияләрне башкара:

- торги үткәрү документларын эшли һәм раслый;
- торги үткәрү турында рәсми чыганакта мәгълүмат бастыра;
- торгида катнашу өчен гаризаларны кабул итә, аларга теркәлү номерларын билгели;
- гаризаларны кабул итү вакыты беткәч, алынган материалларны Комиссиягә тапшыра;
- гаризалар, Комиссия утырышы беркетмәләре, торги үткәрү өчен документлар сакланышы өчен, торги үткәрү документларына үзгәрешләр кертү өчен җаваплы;
- гариза бирүчеләрнең язмача соравы буенча, торги үткәрү документларына аңлатмалар бирә, сорату керү чыганагын күрсәтмичә, бу аңлатмаларны торги үткәрү документлары тәкъдим ителгән барлык гариза бирүчеләргә җиткерә;
- аукцион үткәрү өчен кирәк булган башка функцияләрне башкара.

3.3. Гариза бирүче түбәндәге функцияләрне башкара:

- торги турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән вакыт эчендә, аукцион турында документларда күрсәтелгән формада торгида катнашу өчен гариза бирә. Бер дәгъвачы бер лот буенча торгида катнашу өчен бер генә гариза бирергә хокуклы.
- бирелгән мәгълүматның төгәллеге өчен җаваплы;
- билгеләнгән тәртип буенча, гаризаны тәэмин итү сыйфатында акча кертә;
- торгида җиңгән очракта, торги шартлары буенча җиңүчегә йөкләнгән йөкләмәләрне үти;
- торгины оештыручыга язмача хәбәр итеп, гаризалар кабул итү сроы тәмамланганчы, тапшырылган гаризаны кире кайтарырга хокуклы.

3.4. Торгида җиңүче торги нәтиҗәләре буенча беркетмәгә кул куйганнан соң 10 эш көне эчендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалануга шартнамә төзүгә сатып алынган хокук өчен түләргә тиеш.

3.5. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалануга шартнамә төзү хокукына түләгән торги җиңүчесе күрсәтелгән шартнамәне төзергә һәм билгеләнгән тәртиптә таләп ителгән рөхсәт документациясен рәсмиләштерергә тиеш. Торги заказчысы һәм җиңүче арасында реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалануга шартнамә ун елга төзелә.

## IV. Торги үткәрү формасы

4.1. Аукцион ачык торги формасында үткәрелә.

4.2. Торги турында документлары белән билгеләнгән таләпләрне канәгатьләндергән теләсә кем торгида катнаша ала.

## V. Торгида катнашу шартлары

5.1. Билгеләнгән тәртиптә гаризаны тәэмин итүне кертмәгән гариза бирүче торги катнашучысы була алмый.

5.2. Гариза бирүчене торгида катнаштырудан баш тарталар:

- ул биргән гариза аукцион турында документлар таләпләренә туры килмәгән очракта;
- әлеге нигезләмәдә каралган документлар, торги турында документларны тапшырмаган очракта, яки андый документларда ялган мәгълүмат булган очракта.
- әлеге нигезләмәдә каралган башка очракларда.

## VI. Торги үткәрү турында хәбәрнамә

6.1. Торги үткәрү турында хәбәрнамә рәсми сайтта торгида катнашу өчен гаризалар тапшыру тәмамланганчы кимендә утыз көн кала урнаштырыла.

6.2. Хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- исеме, урыны, почта адресы, электрон почта адресы һәм торги оештыручының элемтә телефоны номеры;
- торги үткәрү урыны, көне һәм вакыты;
- аукцион предметы (реклама конструкциясенең урнашу урыны күрсәтелә);
- аукцион адымы;
- аукцион предметының башлангыч бәясе;
- торгида катнашуга гаризаны тәэмин итү күләме;
- торгида катнашу өчен гаризалар бирү срогы тәмамлануы датасы һәм вакыты;
- гаризаларны карау срогы;
- аукцион турында документ нигезләмәләрен аңлату турында сорату бирү тәмамлану датасы;
- торги оештыручысы торги үткәрүдән баш тартырга хокуклы срок;
- торги җиңүчесен билгеләү өчен шартлар;
- аукцион турында документлар алу тәртибе турында мәгълүмат;
- шартнамәнең гамәлдә булу вакыты.

6.3. Торги оештыручысы аукционда катнашуга гаризалар тапшыру тәмамлануга биш көннән дә соңга калмыйча торги уздыру турындагы хәбәрнамәгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карарны кабул иткән көннән алып бер көн эчендә мондый үзгәрешләр торги оештыручысы тарафыннан торгиның рәсми сайтында урнаштырыла. Шул ук вакытта торгида катнашу өчен гаризалар бирү вакыты шул рәвешле озайтылырга тиеш: торги үткәрү турындагы хәбәрнамәгә кертелгән үзгәрешләрнең торги рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып, торгида катнашу өчен гаризалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр унбиш көннән дә ким булмаска тиеш.

6.4. Торги оештыручысы торгида катнашуга гариза бирү срогы тәмамланганчы биш көннән дә соңга калмыйча торги үткәрүдән баш тартырга хокуклы. Торги

үткәрүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә торги үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә торги рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге карар кабул ителгән көннән алып, ике эш көне эчендә торги оештыручысы барлык гариза бирүчеләргә тиешле хәбәрнамәләр җибәрә. Түләнәчәк акчаның алдан бирелә торган өлешен кертү таләбе куелган очракта, торги оештыручысы гариза бирүчеләргә торгидан баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә түләнәчәк акчаның алдан бирелә торган өлешен кире кайтара.

## VII. Аукцион турында документлар

7.1. Аукцион турында документлар составына керә:

- хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәләр;
- гаризаның эчтәлегенә һәм составына таләпләр һәм аны тутыру буенча инструкция;
- гаризага беркетелә торган документлар исемлеге;
- торгида катнашу өчен гариза бирү тәртибе, урыны, башлану датасы, тәмамлау датасы һәм вакыты;
- гаризаларны кире алу һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары турында белешмәләр;
- торгида катнашуга гаризаларны карау срогы турында белешмәләр;
- торги үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе турында белешмәләр;
- аукцион адымы;
- реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәсе проекты;
- реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукы өчен түләү срогы турында белешмәләр;
- реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен шартнамә имзаланырга тиешле вакыт турында белешмәләр;
- торги катнашучыларына карата таләпләр;
- торгида катнашучыларга аукцион турында документация нигезләмәләрен аңлату шартлары;
- торги җиңүчеләрен билгеләү критерийлары.

7.2. Торги оештыручысы үз инициативасы буенча яки кызыксынган зат соравы буенча аукцион турындагы документларга торгида катнашу өчен гариза тапшыру тәмамланганчы биш көннән дә соңга калмыйча үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә, мондый үзгәрешләр торги оештыручысы тарафыннан торги рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге карар кабул ителгәннән соң ике эш көне дәвамында мондый үзгәрешләр аукцион турында документлар бирелгән барлык гариза бирүчеләргә электрон документлар рәвешендә җибәрелә. Шул ук вакытта аукционда катнашуга гаризалар бирү срогы, аукцион турындагы документларга кертелгән үзгәрешләрне торги рәсми сайтында урнаштырылган көннән башлап, торгида катнашу өчен гариза бирү срогы тәмамлану срогына кадәр кимендә 15 көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш.

VIII. Торгида катнашу өчен гаризалар бирү

8.1. Торгида катнашу өчен гаризалар аукцион турында документлар белән билгеләнгән срокта һәм форма буенча бирелә. Торгида катнашу өчен гариза бирү Россия Федерациясе Граждан кодексының 438 статьясы нигезендә оферта акцепты булып тора.

8.2. Торгида катнашырга теләк белдергән һәм аның шартлары белән килешкән гариза бирүчеләр торги оештыручысына түбәндәге документларны тапшыралар:

- аукцион турында документларда расланган тиешле формага туры килгән торгида катнашуга гариза;

- аукцион турында документлар белән каралган шартларда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзүгә ризалык;

- оешма турында белешмәләр (юридик һәм фактик адрес, ИНН, ОГРН, элемтә өчен телефон номерлары), җитәкче вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләре, җаваплы башкаручының фамилиясен, исемен, атасының исеме, банк реквизитлары һәм алар исәптә торган салым хезмәте турында мәгълүматлар, элемтә өчен мәгълүматлар; фамилиясен, исемен, атасының исемен, паспорт мәгълүматларын, яшәү урыны турында белешмәне, элемтә өчен мәгълүматларны кертеп, физик зат турында белешмәләр; фамилиясен, исемен, атасының исемен, паспорт мәгълүматларын, яшәү урыны турында белешмәне, банк реквизитлары һәм ул исәптә торган салым хезмәте турында мәгълүматлар, элемтә өчен мәгълүматларны кертеп, шәхси эшмәкәр турында белешмәләр;

- мөрәҗәгать итүче - юридик зат яисә индивидуаль эшкуар исеменнән бүтән зат эш итсә, шулай ук физик затка яки физик затларга гариза бирүченең мөһере белән таныкланган һәм җитәкче/эшкуар яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган торгида катнашу буенча гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкаруга бирелгән ышаныч кәгазьләре тапшырыла. Мондый ышаныч кәгазенә җитәкченең вәкаләтле заты кул куйган очракта, мөрәҗәгать итүченең мөһере белән расланган һәм аның җитәкчесе имзалаган әлеге затның вәкаләтләрен раслаучы документның күчермәсе тапшырылырга тиеш;

- торгида катнашуга гаризаны тәэмин итү сыйфатында акчаларны билгеләнгән күләмдә кертүне раслаучы документ.

8.3. Торгида катнашу өчен гаризалар кабул итү турыдан-туры гаризаларны карый башлау алдыннан торги үткәрү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән торгида катнашу өчен гаризаларны карау көнендә туктатыла.

8.4. Торги үткәрү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокта кергән торгида катнашу өчен гаризалар торги оештыручысы тарафыннан теркәлә. Гариза бирүченең таләбе буенча торги оештыручысы, аны алу датасы һәм вакыты күрсәтеп, мондый гариза алуда раслама бирә

8.5. Торгида катнашу өчен гаризалар кабул итүнең билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң алынган гаризалар каралмый.

8.6. Гариза бирүче, бу хакта торги оештыручысына язмача хәбәр итеп, гаризалар кабул итү срогы тәмамланганчы, гаризаны кире алырга хокуклы.

Гаризаны кире алу гаризалар кабул итү журналында теркәлә.

Гариза бирүчегә 5 эш көне эчендә кертелгән гаризаны тәэмин итү акчалары кире кайтарыла.

## IX. Торгида катнашу өчен гаризаларны карау тәртибе

9.1. Аукцион комиссиясе аукцион турында документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына торгида катнашуга гаризаларны карый.

9.2. Торгида катнашу өчен гаризаларны карау срогы гаризалар бирү срогы тәмамланганнан соң ун эш көненнән артып китә алмый.

9.3. Бер гариза бирүченең бер үк лотка карата торгида катнашу өчен ике яки аннан да күбрәк гариза бирүе ачыкланган очракта, элегрәк гариза бирүче тарафыннан бирелгән гаризалар алынмаган булса, әлеге лотка карата бирелгән гаризаларның барысы да каралмый һәм андый гариза бирүчегә кире кайтарыла.

9.4. Аукцион комиссиясе тарафыннан торгида катнашуга гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә гариза бирүчене торгида катнашуга кертү турында һәм гариза бирүчене торгида катнашучы дип тану турында яисә гариза бирүчене торгида катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул торгида катнашу өчен гариза карау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Беркетмә аукцион комиссиясе тарафыннан алып барыла һәм гаризаларны карау тәмамланган көнне утырышта катнашучы барлык аукцион комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәдә гариза бирүчеләр турында белешмәләр, гариза бирүчене торгида катнашырга рөхсәт итү һәм аны анда катнашучы дип тану яки, мондый карарны нигезләп, торгида катнашудан баш тарту турында карар булырга тиеш. Күрсәтелгән беркетмә торгида катнашу өчен гаризаларны карау төгәлләнгән көнне оештыручы тарафыннан торгиның рәсми сайтында урнаштырыла. Гариза бирүчеләргә аукцион комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарлар турында күрсәтелгән беркетмәгә кул куелган көннән дә соңга калмыйча хәбәрнамәләр җибәрелә.

9.5. Торгида катнашуга бер генә гариза да кермәгән, торгида катнашуга бер гариза кергән яки торгида катнашудан барлык гариза бирүчеләр баш тарткан очракта, яисә бер генә гариза бирүчене торгида катнашучы дип тану, барлык гариза бирүчеләрне аукционда катнаштырудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, торги булмаган дип танылa. Торгины оештыручы бердәнбер гариза бирүче яки торгида катнашучы белән торгида катнашуга гариза һәм аукцион турындагы документлар белән каралган шартларда һәм бәядән шартнамә төзергә тиеш, ләкин торгины үткәрү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән шартнамәнең (лотның) башлангыч (минималь) бәясеннән ким булмаган бәядән.

Аукцион турында документлар белән ике һәм аннан күбрәк лот каралган очракта, торги катнаштырудан баш тарту турындагы карар барлык гаризачыларга карата кабул ителгән лотка карата гына торги булмавы танылa.

9.6. Гариза бирүче торгида катнашуга кертелмәгән очракта, торгины оештыручы гаризаларны карау беркетмәсенә имза салынган көннән алып 5 эш көне эчендә гаризаны тәэмин итүгә бирелгән сумманы кире кайтарырга тиеш.

## X. Торгида катнашу өчен гаризаларны финанс тәэмин итү

10.1. Дәгъва кылучылар торги уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән күләмдә, срокларда һәм тәртиптә өлеш акчасын кертә.

Әгәр дәгъвә кылучы берничә лот алырга ниятли икән, һәр лот буенча өлеш акчасы кертелә.

Кирәкле өлеш акчасының керүен раслаучы документ булып банк билгесе белән түләү йөкләмәсе тора.

10.2. Өлеш акчасы түбәндәге очракларда кире кайтарыла:

- торги үткәрү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән гаризалар кабул итү срогы чыкканчы гаризаны кире алу турында торги оештыручырга язмача хәбәр иткән дәгъвачыга рәсми җавап алганнан соң җиде календарь көн эчендә;

- торгида җиңмәгән катнашучыга беркетмәгә кул куйганнан соң җиде календарь көн эчендә;

- торгида катнашырга рөхсәт ителмәгән дәгъвачыга (торгида катнашуга гариза комиссия тарафыннан кире кагылган) комиссия тарафыннан мондый карар кабул ителгәннән соң җиде календарь көн эчендә (беркетмәне имзалау);

- торгида катнашучыга, торги булмады дип танылган (әлеге тәртипнең 13.1 пунктындагы а-в пунктчаларында күрсәтелгән сәбәпләр буенча), һәм бердәнбер катнашучы реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә, транспорт чарасында реклама урнаштыруга шартнамә төзү хокукыннан файдаланмаган очракта, комиссия тарафыннан мондый карар кабул ителгәннән соң җиде календарь көн эчендә (беркетмәне имзалау);

- билгеләнгән тәртиптә торгида катнашуга гариза бирмәгән дәгъвачыга.

10.3. Торги откан зат белән шартнамә төзегәндә, кертелгән өлеш акчасының суммасы реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә, транспорт чарасында реклама урнаштыруга шартнамә төзү хокукын түләү исәбенә исәпләнә.

10.4. Өлеш акчасы түбәндәге очракларда кире кайтарылмый:

- торгида җиңүче торги нәтиҗәләре турында беркетмә имзалаудан качып йөргәндә (баш тартканда);

- торгидада җиңүче билгеләнгән срокта реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзүдән качып йөргәндә (баш тартканда).

## XI. Торги үткәрү тәртибе

11.1. Торгида бары тик торги катнашучылары буларак танылган гариза бирүчеләр генә катнаша ала.

11.2. Торги аукцион комиссиясе әгъзалары һәм торгида катнашучылар (аларның вәкилләре) катнашында торги оештыручысы тарафыннан оештырыла.

11.3. Торги башлангыч бәяне игълан итүдән башлана. Һәрбер алдагы бәя аукцион адымына агымдагы бәяне арттыру белән билгеләнә. Аукцион адымы башлангыч бәянең 10 % тәшкил итә.

11.4. Әгәр агымдагы бәяне өч тапкыр игълан иткәннән соң, катнашучыларның берсе дә югары бәя тәкъдим итмәсә, торги тәмамлана.

Торгида җиңүче дип, торги тәмамланган агымдагы бәяне тәкъдим иткән катнашучы танылa.

11.5. Торги уздырганда, оештыручы мәҗбүри тәртиптә торги аудиоязмасын һәм беркетмәсен алып бара, анда торги үткәрү урыны, датасы һәм вакыты, торгида катнашучылар, контрактның башлангыч бәясе, контрактның бәясе турында соңгы һәм соңгыдан алдагы тәкъдимнәр, атамасы һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), торгида җиңүченең һәм контракт бәясе турында соңгыдан алдагы тәкъдим ясаган

катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны турында (физик зат өчен) белешмә булырга тиеш. Беркетмә катнашучы барлык комиссия әгъзалары тарафыннан торги үткәрелгән көнне имзалана. Беркетмә күрсәтелгән протоколга кул куйганнан соң икенче көнне рәсми сайтта урнаштырыла.

11.6. Өч тапкыр башлангыч бәяне игълан иткәннән соң, торгида катнашучыларның берсе дә тәкъдим ителгән бәядән шартнамә төзү ниятен белдермәгән булса, торги булмады дип санала.

11.7. Торгида җиңүченең беркетмәгә кул куюдан баш тартуы шартнамә төзүдән баш тарту дип санала, бу очракта аларга гаризаны тәэмин итү өчен кертелгән акчалар кире кайтарылмый.

11.8. Беркетмә комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланганнан бирле юридик көч ала һәм җиңүченең рөхсәт алу һәм реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен шартнамә төзү хокукын раслаучы документ булып тора. Беркетмәнең күчермәсе җиңүчегә яки аның вәкаләтле вәкиленә тапшырыла яисә аңа почта аша (заказлы хат белән) беркетмә имзаланган көннән алып 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә. Торгида катнашучылар беркетмә белән танышырга хокуклы.

## XII. Торгига йомгак ясау

12.1. Торгида җиңүче торги нәтиҗәләре буенча беркетмә имзаланганнан соң 10 эш көне эчендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен шартнамә төзүгә сатып алынган хокук өчен түләргә тиеш.

12.2. Торгида җиңүче беркетмәгә кул куюдан яки реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына түләүдән баш тарткан очракта, ул торгидан чыккан дип танылa. Бу очракта гаризаны тәэмин итү өчен кертелгән акча кире кайтарылмый. Комиссия карары буенча, торгида җиңүче дип, чыккан катнашучының тәкъдиме артыннан килүче бәяләр тәкъдим иткән катнашучы аталырга мөмкин яки урын яңадан торгига куелачак яки торгидан алыначак.

12.3. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына түләүче торги җиңүчесе түләгәннән соң 60 эш көне дәвамында түләнгәннән соң әлеге шартнамәне төзергә һәм тиешле тәртиптә рөхсәт документларын рәсмиләштерергә тиеш.

12.4. Аукционның җиңүчесе реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамә төзегәннән соң гына реклама конструкциясен урнаштыра башларга хокуклы.

12.5. Торгида җиңүчедән бәйсез сәбәпләр буенча реклама конструкциясен урнаштыра алмаган очракта (реклама конструкциясен монтажлау буенча эшләрне сезонлы башкару, грунтларның катлаулы геологиясе, килештерүләрне алуның катлаулылыгы һәм башкалар) җиңүченең язма мөрәҗәгате буенча югарыда күрсәтелгән срок 6 айга кадәр озайтылырга мөмкин. Шартнамә төзү вакытын озайту турындагы карар торги оештыручысы тарафыннан кабул ителә.

12.6. Торги үткәрелгәннән соң 10 эш көне эчендә оештыручы торги нәтиҗәләрен рәсми сайтта урнаштырырга тиеш.

12.7. Торгины үткәрү барышында төзелгән беркетмәләр, торгида катнашу өчен гаризалар, аукцион турындагы документлар, аукцион турындагы документларга

кертелгән үзгәрешләр һәм аукцион турындагы документларны аңлату, шулай ук торгиның аудио яки видеоязмасы торги оештыручысы тарафыннан кимендә өч ел саклана.

12.8. Торги булмаган очракта, торги оештыручысы билгеләнгән тәртиптә яңа торги үткәрү турында игълан итәргә хокуклы.

12.9. Яңа торги үткәрү турында игълан ителгән очракта, торги оештыручысы торги шартларын үзгәртергә хокуклы.

12.10. Бу аукцион документлары таләпләрен бозып үткәрелгән торги кызыксынган кешенең дәгъвасы буенча гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

## XIII. Торги узмады дип тану

13.1. Куелган һәр лот буенча аукцион түбәндәге очракларда узмады дип танила:

а) аукционда катнашуга бер катнашучы кертелгән;

б) реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына башлангыч бәяне өч тапкыр игълан иткәннән соң аукционда катнашучыларның берсе дә билетны күтәрмәде;

в) торгида катнашудан барлык дәгъвачылар баш тарткан;

г) аукционда җиңүче аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәне имзалаудан, реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзүдән кача.

13.2. Аукционга заказ бирүче, аукөион узмады дип танылган очракта, аукционны кабат үткәрү турында игълан итәргә хокуклы, шул ук вакытта аның шартлары да үзгәрергә мөмкин. Аукционга заказ бирүче реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен 10 елга шартнамә төзү хокукының башлангыч бәясен киметергә һәм (яки) кабат бәяләү үткәрмичә, аукцион адымын 5 проценттан артык булмаганга киметергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 18 нче гыйнвар
12 нче номерлы карары белән расланган
3 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә
реклама конструкцияләрен урнаштыруга
шартнамәнең типлаштырылган формасы

___ нче шартнамә

Түбән Кама шәһәре «_____» _____________ 20____г.

_______________________________________________________«ТР Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ исеменнән, алга таба «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты» дип аталучы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты, бер яктан, һәм ____________________________ нигезендә эш итүче, ________________________ исеменнән, алга таба «Реклама конструкциясе хуҗасы» дип аталучы _____________________________ икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында чын шартнамә төзеделәр.

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге шартнамә нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты Реклама конструкциясе хуҗасына түләү шарты белән әлеге шартнамәнең 1.2 пунктта күрсәтелгән реклама конструкциясен Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милеккә яисә дәүләт милке хокукы чикләнмәгән һәм әлеге килешү шартлары һәм гамәлдәге законнар нигезендә Реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан тышкы реклама тарату максатларында, җирле үзидарә органнары ия булган эш йөртү хокукына ия гомуми файдаланудагы җир кишәрлегенә кушу хокукы бирә.

1.2. Реклама конструкциясен урнаштыруның адресы:
______________________________________________________________________

1.3. Реклама конструкциясенең мәгълүмат кырының гомуми мәйданы

1.4. Реклама конструкциясе күренеше: ______________________________

1.5. Реклама конструкциясе Реклама конструкциясе хуҗасы атамасын һәм элемтә телефонын, реклама конструкциясен Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннары реестрына керткәндә бирелә торган идентификация номерын күрсәтеп, маркировкага ия булырга тиеш.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының хокуклары һәм бурычлары:

2.1.1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты реклама конструкциясенең техник торышын һәм тышкы кыяфәтен тикшереп торырга хокуклы. Реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәтнең килештерелгән эскиз проектына (паспортка), әлеге төр конструкцияләр өчен законнар белән билгеләнгән техник таләпләргә туры килмәве ачыкланган очракта, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты ачыкланган бозуларны бетерү турындагы таләп җибәрергә хокуклы. Реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан ачыкланган бозуларны бетерү буенча таләптә күрсәтелгән срокта чаралар күрелмәгән очракта, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты административ йогынты чараларын һәм законда яисә әлеге шартнамәдә каралган башка чараларны куллануны гамәлгә ашыручы органнарга җибәрелә торган акт төзергә хокуклы.

2.1.2. Реклама конструкциясен урнаштыруда рөхсәтне гамәлдән чыгарган яки гамәлдә түгел дип таныган очракта, реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясен демонтажлау турында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе биргән көннән алып бер ай эчендә реклама конструкциясен сүтәргә, шулай ук күрсәтмә бирелгән көннән өч көн эчендә мондый реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны бетерергә тиеш.

2.1.3. Айның соңгы көненнән дә соңга калмыйча хезмәт күрсәтү турында акт тапшырырга.

2.1.4. Реклама конструкциясе хуҗасы адресына РФ СКның 168 ст. 3 пунктында күрсәтелгән срокта хисап-фактураны куярга.

2.2. Реклама конструкциясе хуҗасының хокуклары һәм бурычлары:

2.2.1. Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясен урнаштыру урынына каршылыксыз керү һәм Реклама конструкциясе хуҗасының хокукларын, шул исәптән аны монтажлау, эксплуатацияләү, техник хезмәт күрсәтү һәм сүтүне тормышка ашыру белән бәйле максатлар өчен бу урынны файдалану хокукына ия.

2.2.2. Реклама конструкциясе хуҗасы әлеге шартнамәне берьяклы судтан тыш тәртиптә - реклама конструкциясен урнаштыруга түләү буенча бурычы булмаган, аны сүтү һәм аны урнаштыру урынында яңадан торгызу эшләрен башкару шартларында гына, моның турында әлеге шартнамәне өзүнең көздә тотылган датасына кадәр кимендә 15 календарь көн алдан Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итеп өзәргә хокуклы.

2.2.3. Реклама конструкциясе хуҗасы әлеге шартнамә һәм гамәлдәге законнар нигезендә реклама конструкциясен урнаштырырга һәм файдаланырга тиеш.

2.2.4. Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясе эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиеш.

2.2.5. Реклама конструкциясе хуҗасы үз көчләре белән һәм үз хисабына реклама конструкциясен тиешле техник һәм эстетик халәттә тотарга, реклама конструкциясенә килгән зыянны җимерек урыннарны ачыклау вакытыннан 1 календарь көн эчендә бетерергә, монтажлау һәм сүтү эшләрен башкарырга, реклама конструкциясен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны, шул исәптән өченче затларга зыянны каплау чыгымнарын да кертеп, чыгымнарны капларга тиеш.

2.2.6. Реклама конструкциясе хуҗасы эскиз проекты (паспорт) нигезендә, тәүлекнең караңгы вакытында реклама конструкциясен көн саен яктыртуны тәэмин итәргә тиеш.

2.2.7. Реклама конструкциясе хуҗасы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы һәм «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен тышкы төзекләндерү һәм санитар тәртиптә тоту кагыйдәләре нигезендә реклама конструкциясен урнаштыру урынын тиешле хәлдә төзекләндерүне үз вакытында гамәлгә ашырырга тиеш.

2.2.8. Реклама конструкциясе хуҗасы әлеге шартнамә нигезендә кабул ителгән түләү йөкләмәләрен тиешенчә тормышка ашырырга тиеш.

2.2.9. Реклама конструкциясе хуҗасы әгәр дә әлеге бурыч әлеге төр конструкцияләргә карата законнарда каралган булса, куркынычсызлык шартлары буенча реклама конструкциясенең торышына техник экспертиза үткәрергә тиеш.

2.2.10. Реклама конструкциясе хуҗасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мөрәҗәгате буенча ел дәвамында мәгълүмат таратуның 5 проценты күләмендә реклама конструкциясендә шәһәр мәгълүматын һәм социаль рекламаны бәйрәм, истәлекле даталар һәм социаль әһәмияткә ия проектлар буенча урнаштырырга бурычлы. Монтажлау, сүтү, шулай ук социаль реклама урнаштыру эшләре Реклама конструкциясе хуҗасы хисабына башкарыла.

2.2.11. Реклама конструкциясе хуҗасы нигезе күмелгән аерым торучы реклама конструкциясен урнаштырган очракта, җир эшләре башкарырга ордер алырга тиеш.

2.2.12. Реклама конструкциясе хуҗасы Яклар тарафыннан кабул итү актын имзалау өчен аны урнаштыру вакытыннан 1 эш көне эчендә реклама конструкциясен урнаштыру турында (шул исәптән вакытлыча сүтелгәннән соң) Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына язмача хәбәр итәргә тиеш. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан урнаштырылган реклама конструкциясендә җитешсезлекләр ачыкланган очракта, Реклама конструкциясе хуҗасы аларны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәткән срокта бетерергә тиеш.

## 3. ТҮЛӘҮЛӘР ҺӘМ ИСӘП-ХИСАПЛАР

3.1. Реклама конструкцияләрен урнаштыру бәясе торги үткәрү нәтиҗәсендә билгеләнде, торги нәтиҗәләре буенча беркетмәгә кул куелганнан соң 10 эш көне эчендә җинүче түләргә тиеш булган сумма_______ сум тәшкил итә.

3.2. Реклама конструкциясен урнаштыру өчен айлык түләү күләме әлеге шартнамәгә 1 нче кушымтада билгеләнгән.

3.3. Реклама конструкциясе хуҗасы ай саен исәп-хисап аеның соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләргә тиеш.

3.4. Түләү әлеге шартнамәдә күрсәтелгән счетка акча күчерү юлы белән акча тлщнми торган тәртиптә башкарыла.

3.5. Түләү датасы булып, түләүче счетыннан банк билгесе белән түләү документы белән исбатланган акча күчерү датасы санала. Түләү факты - әлеге шартнамәдә күрсәтелгән счетка түләү суммасын күчерү.

3.6. Реклама конструкциясен урнаштыру өчен түләү күләмен үзгәртү Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла. Түләү

күләмен үзгәртү турында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты бер ай эчендә хәбәр итәргә тиеш. Шул ук вакытта Яклар әлеге шартнамәгә өстәмә килешү имзаларга тиеш. Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясен урнаштыру өчен түләү күләмен үзгәртә торган өстәмә килешүгә кул куюдан баш тарткан очракта, әлеге шартнамә реклама конструкциясен урнаштыру өчен яңа түләү күләме күздә тотылган датадан өзелгән дип санала.

## 4. ШАРТНАМӘНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ

Әлеге шартнамә имзалану вакытыннан үз көченә керә һәм 20____ елның «_____» _________________кадәр гамәлдә була.

## 5. ШАРТНАМӘНЕ ГАМӘЛДӘН ЧЫГАРУ ТӘРТИБЕ

5.1. Әлеге шартнамә Яклар килешүе буенча өзелергә мөмкин

5.2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге очракларда әлеге шартнамәне берьяклы судтан тыш тәртиптә өзәргә хокуклы:

5.2.1. Реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан түләү кертелмәү, шулай ук әлеге шартнамәдә каралган түләү срогында тулы булмаган күләмдә кертү, әгәр түләүнең срогы чыгу 30 календарь көннән артык булса;

5.2.2. Реклама конструкциясе хуҗасының социаль реклама урнаштырудан баш тартуы;

5.2.3. Реклама конструкциясе хуҗасын 12 ай эчендә 1 тапкыр административ хокук бозулар турында гамәлдәге законнарда каралган реклама конструкциясен карап тотуга таләпләрне бозган өчен аминистратив җаваплылыкка тарту;

5.2.4. Гамәлдәге Россия Федерациясе законнары нигезендә реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәтне гамәлдә түгел дип тану яисә рөхсәтне гамәлдән чыгару.

5.3. Әлеге шартнамәнең 5.2 пунктында каралган әлеге шартнамәне берьяклы өзү өчен нигезләр булганда, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты шартнамәдә күрсәтелгән адрес буенча, әлеге шартнамәне берьяклы тәртиптә өзү турында Реклама конструкциясе хуҗасына язма хәбәрнамә җибәрә. Бу очракта әлеге шартнамә мондый хәбәрнамә алынган датадан соң өзелгән дип санала.

5.4. Әгәр торак пунктны яки шәһәрне планлаштыруны үзгәртү, реклама конструкцияләрен төзүгә, территориаль урнаштыруны оптимальләштерүгә бәйле сәбәпләр аркасында реклама конструкциясен демонтажлау яки күчерү зарурлыгы туса, Реклама конструкциясе хуҗасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты таләбе буенча әлеге чараларны тормышка ашырырга тиеш. Шул ук вакытта торак пунктны (шәһәрне) планлаштыруны үзгәртүгә һәм (яки) төзелешкә бәйле рәвештә сүтү яки күчерү кирәк булган очракта, Реклама конструкциясе хуҗасына, булган мөмкинлекләргә карап, алмашка шундый ук реклама конструкциясен урнаштыру өчен башка урын бирелергә тиеш. Реклама конструкцияләрен территориаль урнаштыруны оптимальләштерүгә бәйле рәвештә сүтү яки күчерү зарурлыгы очрагында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты Реклама конструкциясе хуҗасына шундый ук конструкцияне урнаштыру өчен башка урын бирергә тиеш. Шул ук вакытта, конструкцияне сүтеп бетергәннән алып аны торгызуга ко-

мачаулый торган эшләр тәмамланганчы реклама конструкциясен урнаштыру өчен түләү алынмый.

5.5. Әлеге шартнамәнең гамәлдә булу срогы чыкканда яки вакытыннан алда өзелгәндә, Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны 1 календарь көн эчендә бетерергә һәм реклама конструкциясен 10 календарь көн эчендә сүтәргә бурычлы.

5.6. Әлеге шартнамәне өзгәндә һәм Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны бетерү һәм әлеге конструкцияне демонтажлау буенча йөкләмәләрен үтәмәгәндә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты, Реклама конструкциясе хуҗасына мәгълүматны бетерүгә, демонтажлауга, реклама конструкциясен урнаштыру урынында торгызу эшләре, саклау һәм, кирәк булганда, реклама конструкциясен юк итү белән бәйле акылга ярашлы чыгымнарны йөкләп, реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны бетерүне һәм конструкцияне демонтажлауны гамәлгә ашыруга хокуклы. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты реклама конструкциясе хуҗасы алдында мәгълүматны бетерү һәм сүтү аркасында килеп чыккан зыян өчен җаваплылыкны үз өстенә алмый. Реклама конструкциясен юк итү, әгәр Реклама конструкциясе хуҗасы аны саклау урыныннан алмаган һәм мәгълүматны бетерү, демонтажлау, реклама конструкциясен урнаштыру урынында торгызу эшләре һәм аны саклау буенча тотылган чыгымнарны капламаган очракта, демонтаж гамәлгә ашырылганнан соң, 10 календарь көннән соң башкарылырга мөмкин.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

6.2. Түләү сроклары бозылганда, Реклама конструкциясе хуҗасына срогы чыккан һәр көн өчен бурычның 0,06% күләмендә пеня исәпләнә.

6.3. Реклама конструкциясен урнаштырмаган яки реклама конструкциясендә реклама мәгълүматлары булмаган очракта, Реклама конструкция хуҗасы әлеге шартнамә шартлары буенча тиешле түләүдән азат ителми.

## 7. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

7.1. Аның гамәлдә булу чорында әлеге шартнамә Якларның үзара килешүе буенча үзгәртелергә яки тулыландырылырга мөмкин. Әлеге шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр ике як тарафыннан да әлеге шартнамәнең аерылгысыз өлешенә әверелгән өстәмә килешүгә кул куеп ясала.

7.2. Әлеге шартнамә белән җайга салынмаган Якларның үзара мөнәсәбәтләре гамәлдәге законнар белән регламентлана.

7.3. Әлеге шартнамәдән килеп чыга торган бәхәсләр Татарстан Республикасы Арбитраж судында гамәлдәге законнар нигезендә, бәхәсне җайга салуның дәгъва тәртибе үтәлгәннән соң карала. Дәгъваны карау вакыты - аны алганнан соң 30 календарь көн.

7.4. Яклар биш көнлек сроктан да соңга калмыйча үз реквизитларының теләсә нинди үзгәреше, шулай ук җитәкченең үзгәрүе турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

7.5. Яклар бер-берсенә хатны (хәбәрнамәләр, таләпләр) тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән яисә раслама белән турыдан-туры адресатка тапшыру, шулай ук факсимиль элемтә буенча җибәрергә хокуклы. Әгәр дә хат (хәбәрнамә, таләп) адресатка почта аша җибәрелсә, күрсәтелгән адрес буенча адресат булмаган очракта да, адресатның соңгы билгеле булган урнашу урыны буенча җибәрелгән очракта, адресат хатны (хәбәрнамә, таләп) алган дип санала. Әгәр дә хат (хәбәрнамә, таләп) факсимиль элемтәсе буенча адресатка җибәрелсә, әлеге шартнамәдә күрсәтелгән факс номеры буенча җибәрелгән очракта, адресат хатны (хбәрнамә, таләп) алган дип санала.

7.6. Әлеге шартнамә тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә (һәр як өчен берәр нөсхә) төзелгән.

## 8. ЯКЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ ҺӘМ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты | Реклама конструкциясе хуҗасы: |
| Почта адресы ___________________ | Почта адресы_____________________________ |
| ________________________________ | _________________________________________ |
| Электрон почта адресы: | Электрон почта адресы: |
| ______________________ | ______________________ |
| Телефон (факс)____________________________ | Телефон (факс)______________________________ |
| Банк реквизитлары: | Банк реквизитлары: |
| ИНН___________________________ | ИНН__________________________________ |
| р/с_______________________________ | р/с___________________________________ |
| КПП___________________________ | КПП__________________________________ |
| БИК_____________________________ | БИК__________________________________________ |

20____ елның ___ ________төзелгән
____ номерлы шартнамәгә
1 нче кушымта

_____________________________________________ исеменнән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты, бер яктан, һәм _________________________________________________нигезендә эш итүче, _____________________________________________ исеменнән алга таба «Реклама конструкциясе хуҗасы» дип аталучы _____________________________________________________, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Кушымта төзеделәр:

| т/с | Урнашу урыны, адресы | Форматы (м) | Яклар саны | Бу вакыт ара-лыгында бәясе (сумнарда) | Шартнамәнең гамәлдә булу ва-кыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| Барысы: | | | | | |

1. Айлык түләү ______________________ сум тәшкил итә, НДС салынмый.
2. Әлеге кушымта югарыда күрсәтелгән Шартнамәгә өстәмә килешү статусына ия һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора.

ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты
_______________/_______________
М.У.

Реклама конструкциясе хуҗасы
____________ /______________
М.У.